Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

12 апрель, 2023 ел № 224

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 25 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган (2019 елның 05 декабрендәге 235 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 27 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү тәртибе» 6 өлешнең 6.2 пунктындагы 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе)»сүзләре белән алыштырырга;

- «район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 9 нчы өлешнең 9.2 пунктындагы 2 пунктчасының 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты сүзләрен» «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов